Шәһәр күләмендә химия фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
8 нче сыйныф

Эш вакыты – 180 минут
Гомуми балл – 100

1 нче бирем. ***(20 балл)***

Түбәндә атамалары бирелгән матдәләрнең формулаларын языгыз:

1) Сөяк оны;
2) Кальцинирланган сода;
3) Зәһәр калий;
4) Яндырылган магнезия;
5) Пирит;
6) Кызыл кан тозы;
7) Яшел хром;
8) Кургаш ялтыравыгы;
9) Сары кан тозы;
10) Татлы кургаш.

2 нче бирем. ***(20 балл)***

Өч пробиракада натрий хлориды, натрий карбонаты, натрий сульфаты эремәләре бирелгән. Шулай ук барий хлориды һәм хлорид кислотасы эремәләре бар. Әлеге өч эремәне танып белүнең тәртибен, реакция тигезләмәләрен һәм күзәтүләрегезне языгыз.

3 нче бирем. ***(20 балл)***

Түбәндәге әверелешләрне башкарырга мөмкинлек биргән реакция тигезләмәләрен языгыз:



4 нче бирем. ***(20 балл)***

Түбәндәге реакция тигезләмәләренең схемаларына коэффициентлар куеп языгыз:

1. $KMnO_4 + HBr \rightarrow MnBr_2 + KBr + Br_2 + H_2O$;
2. $CrO_3 + HCl \rightarrow CrCl_3 + Cl_2\uparrow + H_2O$;
3. $Cu_2O + HNO_{3(куерт.)} \rightarrow Cu(NO_3)_2 + H_2O + NO_2\uparrow$;
4. $Zn + HNO_{3(сыег.)} \rightarrow Zn(NO_3)_2 + NH_4NO_3 + H_2O$;
5. $FeS_2 + O_2 \rightarrow Fe_2O_3 + SO_2\uparrow$.

5 нче бирем. ***(20 балл)***

Әгәр практик чыгыш 80%-ны тәшкил итсә, 800 г тимер (III) оксидыннан күмер ярдәмендә нинди масса тимер табып була?